# АРЧА ХӘБӘРЛӘРЕ

Газета 1930 елдан чыга

№48 (10906)

Арча муниципаль районының иҗтимагый-сәяси газетасы

чәршәмбе

5

июль 2017

Һава торышы: 6 июльдә болытлы, яңгыр, көндез +14, төнлә +11 градус/USD – 59,23 сум/EURO – 67,30 сум

arskmedia.ru


КӨН ТЕМАСЫНА

# АРЧАГА ЛӘКЛӘКЛӘР КИЛГӘН



ТУКТАМАС ҖИРЕҢНӘН ТУКТАРСЫҢ! Автор фотосы. 3 июль 2017 ел

**Урамнар да кәефне күтәрә ала. Көзгә як, бертуктаусыз яңгыр төти. Күңелсезләнеп кенә барганда бер урам коймасына ясалган кояш игътибарны җәлеп итте. Янәшәсенә "Исәнме, кояш!" дип тә язып куйганнар. Беләсезме, менә шунда күңел кыллары тибрәнеп куйды, кәеф күтәрелде, көн дә яктырып киткәндәй булды.**

Узган якшәмбедә шәһәребезнең Левитан урамыннан үтәргә туры килде. Бу урамга кергәнче аз гына чигенеш ясап алыйк әле.

Моннан унбиш–егерме еллар элек Арча урамнарында чәчәк үстереп буласына берәү дә ышанмый иде. Актанышка барып андагы хозурлыкка сокланып кайтучылар да баштарак: "Бездә барып чыкмас, өзеп бетерерләр чәчәкне", – дигән фикердә иделәр. Күп каршылыклар белән керде бу яңалык. Күзләребез дә алабутага ияләнгән иде шул, аннан аерылуы читенрәк тоелды. Аның каравы, бүген шәһәр урамнары гына түгел, кайбер капка төпләре чәчәккә күмелгән. Бакчасында чәчәк үстермәгән кеше бармы икән бүген?

Левитан урамында өлкән яшьтәгеләр һәм инвалидлар йорты (аның бакчасы да гөлбакча) каршында яшәүче Гөлүсә Вәлиуллиналарның капка төбе, йорт–бакчалары – үзе кояш кебек. Һәр елны бит бу, күпме хезмәт, тырышлык кирәк моның өчен! Бу урамның үз кояшы бар!

Әлеге гүзәллеккә сокланып китеп барганда тагын бер капка төбендәге манзараны күреп тукталып калдым. Үзе бер әкият дөньясы! Чәчәкләр, куаклар арасында каеннан ясалган җигүле ат, эскәмиядә ял итеп утыручы малай белән кыз һ.б.

– Кичләрен монда кеше күп җыела, – ди йорт хуҗасы Әхмәт Хәкимҗанов. – Болай, карау өчен киләләр. Әнә безнең ләкләкләр дә бар әле, – дип ишегалдындагы агач башына күрсәтте. Үзе әйтмәсә, чын дип уйларсың!

Һәр яңалык авырлык белән керә, дидек. Игътибар иткәнсездер, быел шәһәрнең Шәрык өлешендә чүп контейнерлары янында "Чиста шәһәр" дип язылган үтә күренмәле контейнер барлыкка килде.

– Пластмасс шешәләр өчен ике урынга куйдык без аларны, – ди "Җилкомбытсервис" ширкәте җитәкчесе Альберт Хәкимов. – Тагын берсе станциягә куелды.

– Нәтиҗәсе ничек? Ул шешәләрне кая куясыз, бу яңалыкның файдасы бармы?

– Әкренләп ияләнәләр, баштарак төрле чүп салып китүчеләр дә бар иде. Контейнер тулгач аларны полигонга илтәбез, шунда пресслыйбыз. Мондый шешәләр җир астында меңәр ел ятса да череми бит. Алар хәзер теләсә кайда аунап ята, табигатьне пычрата. Күпмедер өлешен җыйный алсак та бик игелекле гамәл булачак бу. Киләчәктә мондый контейнерларны арттырачакбыз.

Һәр елны дөнья буенча 25 миллиард тонна калдыклар җыйнала, дип исәплиләр. Шәһәрләр өчен чын казага әйләнеп бара бу проблема. Авылларда да ул күләме белән генә аерыла. Су буйларында, агач араларында пластмасс шешәләр ауный. Чәчәк үстерергә өйрәнгән кешеләр тора–бара бу проблеманы да хәл итә алырлар, дигән өметтә калыйк. Район Сабантуе үткәч тә әнә балалар ничә көннәр мәйдан җыештыра иде. Соңгы елларда бу яктан да хәл яхшыра төште, сәүдәгәрләр генә үз артларыннан чисталык калдырырга өйрәнеп бетә алмый.

**Ильяс ФӘТТАХОВ**

ЯҢАЛЫКЛАР

**ИГЪТИБАР!**

Арча район Сабантуе 8 июльдә 10 сәгатьтә башлана.

Ат чабышы сәгать 11.30да башлана. Теркәү 11дә тәмамлана. 0+

**МӨХТӘРӘМ ЯКТАШЛАР! Кадерле кунаклар!!!**

8 июль көнне Арча районы Симетбаш авылында күпләргә билгеле "Симетбаш җыены" узачак! Программада: милли уеннар, мавыктыргыч ярышлар, кызыклы аттракционнар, татар эстрадасының танылган артистлары чыгышлары. Бәйрәм сәгать 16да башлана. "Симетбаш җыены"на рәхим итегез!!! 0+

**ХӨРМӘТЛЕ РАЙОНДАШЛАР!!**

8 июль көнне "Ак барс" агрокомплексы" ширкәте Сикертән авылында узачак "Авыл көне" бәйрәменә чакыра. Бәйрәмебезне Данир Сабиров алып барачак. Башлана 13 сәгатьтә. Рәхим итегез. 0+

**ӘБУНӘЧЕЛӘР ИГЪТИБАРЫНА!**

1 июльдән 2018 елның беренче яртыеллыгына газета–журналларга алдан язылу (1 июльдән 31 августка кадәр) башланды. "Арча хәбәрләре"нә язылу бәясе 616,44 сум. Газетага почта бүлекчәләрендә язылырга мөмкин.

ИЗГЕ БУРЫЧ

# ИСӘН–САУ КАЙТЫГЫЗ!

**Әйләнә дә килә язлар, әйләнә дә килә җәйләр... 30 июньдә хәрби комиссариатта үткән быелгы язгы чакырылышта иң ахыргылардан булып киткән 15 егетне армия сафларына тантаналы озату кичәсендә шушы җыр сүзләре искә төште.**

Әле күзен генә озаткан идек үзләрен, ни арада язгысы килеп җитеп, үтеп тә китте. Бер ел гына хезмәт итәләр, дибез. Әмма әле җылы кочакларыннан чыгарга да өлгермәгән йөрәк парәләреннән шул вакытка гына аерылышу да әти–әниләр өчен җиңел әйбер түгел шул.

– Китәләр, исән–сау әйләнеп кайталар, Аллага шөкер. Күпме мактасалар да, белеп торыгыз, сез ялга түгел, хезмәт итәргә китәсез. Ә Ватанны саклау ул – һәр ир–егетнең изге бурычы. Әти–әниләрегезне кочагыгызга алып, рәхмәтегезне белдерсәгез, аларның хәер–фатыйхасын алсагыз иде, – диде Раил хәзрәт Гыйлаҗев, булачак солдатларга мөрәҗәгать итеп.

– Хезмәт итү җиңелрәк булсын өчен без кулдан килгәнне эшләргә тырыштык. Мәктәптән үк әзерлек эшләре алып барыла, хәрби җыеннар оештырыла. Егетләрнең барысының да үзләре теләп армиягә барабыз дип торулары үзе мактауга лаек. Әти–әниләр, сау–сәламәт, илебез сагына басарга әзер егетләр үстергәнегез өчен зур рәхмәт сезгә. Егетләрнең кая китәселәре Казанда җыелу пунктында гына билгеле була. Кая гына булсагыз да, чын егет икәнлегегезне күрсәтегез, әти–әниегез, район горурланырлык итеп хезмәт итегез, туган ягыгызны, йортыгызны онытмыйча, исән–сау әйләнеп кайтыгыз. Ә без, үз чиратыбызда, сезне ел дәвамында игътибар үзәгендә тотачакбыз, – диде ТР хәрби комиссариатының Арча һәм Әтнә районнары буенча бүлек җитәкчесе Алмаз Борһанов.

– "Ир кеше буларак, мин армиядә хезмәт итәргә тиеш. Бабай да, әти дә хәрби хезмәттә булган бит", – диде Раушан. Алдан ук әзерләнде. Герләр, штангалар алып куйды. Аграр университетта дипломны яклады гына әле. Кайткач инженер–технолог булып эшлим, магистратурага укырга керәм, дип хыялланa, – диделәр Арчадан Гөлсинә һәм Хәбир Абдуллиннар.

– Безнең Адель дә әле генә бишлегә диплом яклады. Булачак юрист. "Бөтен дусларым китте, мин генә калмам", – ди. Дөньялар тыныч бит, куркыныч түгел. Бурычын үтәсен. Исән–сау йөреп кайтсыннар, – диде шулай ук Арчадан Әлфия Сабирова.

Егетләрне район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Рамил Гарифҗанов котлады, изге теләкләрен җиткерде, хакимият тарафыннан әзерләнгән бүләкләрне тапшырды. Әфган сугышында катнашкан отставкадагы офицер, "Сугышчан туганлык" оешмасы җитәкчесе Сергей Баһаветдинов 2–3 ел хезмәт иткән чорлар белән бүгенге армия хезмәтен чагыштырып күрсәтте, киңәшләрен әйтте. Раил хәзрәт хәерле юл теләп дога кылды.

Хәрби комиссариат бинасыннан чыгып барганда солдат киеменнән бер егет белән капма–каршы очраштык. Күкчә Бирәзәдән Азат Исламов булып чыкты ул. Әле армия сафларында хезмәт итеп кайтып кына килеше икән, беренче эш итеп туп–туры хәрби комиссариатка кергән. Әтисе Илдус һәм абыйсы Алмаз каршы алган үзен.

– Башта Свердловск өлкәсендә булдым. Аннан Кавказга җибәрделәр. 13 тонналы танк кебек "БМП–2" дигән хәрби техникада механик–йөртүче булдым, – диде ул. – Армиядә бернинди курка торган әйбер юк. Командирларны тыңларга, әйткәнне үтәргә генә кирәк. Егетләргә киңәшем шул. Теләгем – исән-сау хезмәт итеп кайтсыннар.

**Гөлсинә ЗӘКИЕВА**